Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Бикчурай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

29 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 29 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:
“Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, торак пунктта теркәлгән, әмма теркәү урыны буенча 5 елдан артык яшәмәүче гражданнардан гайре ) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:
- Бикчурай торак пункты территориясендә энергия саклаучы лампаларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- Торак пунктны су белән тәэмин итү;
-Торак пункт юлларын ремонтлау, кышкы карап тору һәм хезмәтләр өчен түләү.
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 108 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 48 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 3 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Бикчурай авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, торак пунктта теркәлгән, әмма теркәү урыны буенча 5 елдан артык яшәмәүче гражданнардан гайре ) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга:

- Бикчурай торак пункты территориясендә энергия саклаучы лампаларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- торак пунктны су белән тәэмин итү;

-торак пункт юлларын ремонтлау, кышкы карап тору һәм хезмәтләр өчен түләү;

-зиратны карап, чистартып торуга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Югары Мәшләк авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Заһидуллин М.Г.

Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы: Заһидуллин М.Г.